ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 22 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 1 – 2, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр башкару капиталь ремонт өчен кертемнең әлеге Законның 9 статьясы нигезендә билгеләнгән минималь күләменнән чыгып булдырылган капиталь ремонт фонды акчалары исәбеннән финанслана торган әлеге хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлеге үз эченә Россия Федерациясе Торак кодексының 166 статьясындагы 1 өлешендә каралган хезмәт күрсәтүләрне һәм (яисә) эшләрне ала. Хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең әлеге исемлегенә кертелгән хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган методик тәкъдимнәр нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнә.»;

2) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«1[1]. Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлегенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә фасадны җылыту, җылләтелми торган түбәне җылләтелә торган түбә итеп үзгәртеп кору, түбәгә чыгу юлларын ясау, коммуналь ресурслар куллануны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләрне исәпләүнең автоматлаштырылган мәгълүмат-исәп системаларын урнаштыру, коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен кирәкле ресурслар куллануны исәпләүнең күмәк (гомумйорт) җайланмаларын һәм әлеге ресурсларны (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, газ) куллануга идарә итү һәм аны җайга салу узелларын урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр, башка төр хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр өстәлергә мөмкин.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 09 март
№ 12-ТРЗ